| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2016 Казан ш. № 5-12/тэ

"РСУ" җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан күрсәтелгән җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "РСУ" җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан күрсәтелгән җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карарның үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2016 № 5-12/тэ
карарына кушымта

“РСУ” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан күрсәтелгән җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, җайга салучы оешма исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык йөртү төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | “РСУ” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифларга дифференциация ясалмаган очракта | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | карарның үз көченә кергән көннән алып 31.12.2016 кадәр | 296,47 | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге